ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.05.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1151**

Яшь гаиләләргә торак сатып алуга бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләп чыгару өчен, 2021 елның икенче кварталына Зеленодольск муниципаль районы буенча торакның бер квадрат метр гомуми мәйданының нормативын билгеләү турында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2021 елның 26 февралендәге «2021 елның II кварталына Россия Федерациясе субъектлары буенча торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» №94/пр Боерыгы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы буенча гомуми торак мәйданының бер квадрат метры хакының 2021 елның икенче кварталына торак сатып алуга яшь гаиләләргә бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен нормативны 55 914 (илле биш мең тугыз йөз ундүрт) сум күләмендә билгеләргә.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А. Матвеевага йөкләргә.

Җитәкче И.Р. Ганиев